**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

01.02.2021 № 71

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 07.09.2020 ел, № 706 карарына үзгәрешләр кертү турында

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 17.06.2020 ел, №413 карары һәм «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычлар булу (булмау) турында салым түләүчеләргә мәгълүмат бирү эшен оештыру турында» 27.01.2021 ел, №47 карары нигезендә, Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 07.09.2020 ел, № 706 карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында:

2.6 пунктка түбәндәге эчтәлекле пункт өстәргә:

«9) Россия Федерациясе бюджет системасы - Россия ФСХ бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында мәгълүматлар»;

2.8 пунктны түбәндәге эчтәлекле пункт белән тулыландырырга:

«7) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булу»;

3.4.1 пунктны түбәндәге эчтәлекле пункт белән тулыландырырга:

«9) законнарны бозган өчен салымнар, җыемнар, пенялар һәм штрафлар түләү буенча бурычлар булу (булмау) турында белешмәләр».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Хәмзин